# Дару үләннәре



# ДАРУ ҮЛӘННӘРЕ ТУРЫНДА ТАБЫШМАКЛАР

Мин үзем – зәһәр инде,
Чагамын кул тидерсәң.
Шаянрак балаларны
Үрле – кырлы сикертәм.

# КЫЧЫТКАН



Исемем сәер булса да
Мине бик хөрмәтлиләр.
Киселсә дә, канаса да,
Иң әйбәт дару диләр.

# БАКА ҮЛӘНЕ (ЯФРАГЫ)



Күләгәдә, урманда чәчәксез дә үсә бу үлән.

# АБАГА



Энҗедәй чәчәк атам мин
Яз көнендә урманда
Миңа берни дә кирәкми
Күләгәлек булганда.

# ЭНҖЕ ЧӘЧӘК



Сары төсле – бал кебек,
Ак чуклары – кар кебек.
Әллә ничә авыруга
Файдасы бар, эч белеп.

# АК ЧӘЧӘК (РОМАШКА)

